ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, , 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче Подгорный торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәгә таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 13 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Подгорный бистәсе, Үзәк урам, 22А йорт адресы буенча урнашкан Подгорный торак пункты КФҮ бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Подгорный торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, махсус хәрби операция катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- Подгорный торак пунктында су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су җыю башнясын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина янында киртәләр кору, төзелеш материаллары сатып алу, скважина насосы белән идарә итү щитын сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Подгорный торак пунктында традицион Күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү (зират территориясен киртәләп алу, төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Подгорный торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек юлларын карап тоту, юлларны кардан чистарту, грейдерлау, ягулык-майлау

материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

- Подгорный торак пунктындагы торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, гомуми файдаланудагы территориядә үлән чабу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитетына Подгорный торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әгълиева